ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**26.01.2023**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 102**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 02 ноябрендәге 2747 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районы физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 сентябрендәге 1002 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын үтәү йөзеннән, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2021 елның 02 ноябрендәге 2747 номерлы карары белән (Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 13 гыйнварындагы 28 номерлы, 2022 елның 28 декабрендәге 3591 номерлы карарларына кертелгән үзгәрешләр белән) расланган, Зеленодольск муниципаль районы физик культура һәм спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә, кушымта нигезендә, үзгәрешләр кертергә.
2. Учреждение җитәкчеләренә үз локаль актларын әлеге карарга туры китерергә.
3. Әлеге карарның гамәлдә булуын 2023 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга.
4. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль район Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә буенча бүлегенә «Интернет» челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр составындагы Зеленодольск муниципаль районы рәсми порталында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А.В.Старостин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының 2023 елның
26 гыйнварындагы 102 номерлы
карарына кушымта

Зеленодольск муниципаль районының муниципаль физик культура һәм спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр

1.1. II бүлекне түбәндәге редакциядә бирергә:

"II. Муниципаль физик культура һәм спорт оешмалары хезмәткәрләренең база окладларын билгеләү

1. Физик культура һәм спорт муниципаль оешмаларының физик культура һәм спорт хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазифа атамасы | Аена база оклад күләме, сумнарда | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | бакалавр, белгеч яки магистр дипломы белән расланган югары белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Физик культура һәм спорт хезмәткәрләре вазыйфаларының беренче дәрәҗәдәге һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Спорт залы буенча дежур | 15 279 | - | - |
| Икенче дәрәҗәдәге физик культура һәм спорт хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Җайлаштырылган физик культура | 15 279 | 16 142 | 18 362 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | инструкторы | | | |
| | Спорт инструкторы | - | 16 142 | 18 362 |
| | Спортчы-инструктор | 15 279 | - | - |
| | Спорт техникасын эксплуатацияләү һәм ремонтлау техникы | - | 16 142 | - |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Җайлаштырылган физик культура буенча инструктор-методист | - | 16 149 | 18 382 |
| | Физкультура-спорт оешмалары инструкторы | - | 16 149 | 18 382 |
| | Тренер | - | 16 149 | 18 382 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Физкультура-спорт оешмалары өлкән инструктор-методисты | - | 16 155 | 18 394 |

2. Физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары мәгариф хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазифа атамасы | Аена база оклад күләме, сумнарда | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, | бакалавр, белгеч яки магистр дипломы белән расланган югары белем |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | тулы булмаган югары белем | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Педагогик хезмәткәр вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Физик культура буенча инструктор | - | 16 142 | 18 362 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Инструктор-методист | - | 16 149 | 18 382 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Методист | - | 16 155 | 18 394 |
| | Өлкән инструктор-методист | - | 16 155 | 18 394 |
| Структур бүлекчә җитәкчеләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Кабинет, лаборатория, бүлек, бүлекчә, сектор, укыту-консультация пункты, укыту (укыту-җитештерү) остаханәсе һәм балаларга өстәмә белем бирү уку-укыту программасын гамәлгә ашыра торган башка структур бүлекчә мөдире (начальнигы) (икенче квалификация дәрәҗәсенә караган структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларыннан тыш) | - | - | 18 463 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Белем бирү программасын һәм балаларга өстәмә белем | - | - | 18 526 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | бирү программасын гамәлгә ашыручы аерымланган структур бүлекчә мөдире (начальнигы) | | | |

3. Муниципаль физик культура һәм спорт оешмалары медицина хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазифа атамасы | Аена база оклад күләме, сумнарда |
|---|---|---|
| "Урта медицина һәм фармацевтика персоналы" һөнәри квалификация төркеме | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Шәфкать туташы | 17 200 |
| | Массаж буенча шәфкать туташы | |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән шәфкать туташы<*> | 18 900 |
| "Табиблар һәм провизорлар" һөнәри квалификация төркеме | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Табиб-белгечләр (өченче һәм дүртенче квалификация дәрәҗәләренә кертелгән табиб-белгечләрдән тыш) | 20 600 |
| "Югары медицина һәм фармацевтика белеме булган учреждениеләрнең структур бүлекчәләре җитәкчеләре (табиб-белгеч, провизор)" профессиональ квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Структур бүлекчә (бүлек, бүлекчә, лаборатория, кабинет, отряд һ.б.) мөдире (стационарларның хирургия юнәлешендәге бүлекләре мөдирләреннән тыш) | 23 400 |

--------------------------------

<*> Вазифа оешмада өч һәм аннан да күбрәк шәфкать туташы булган очракта билгеләнә.

4. Муниципаль физик культура һәм спорт оешмалары мәдәният хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазифа атамасы | Аена база оклад күләме, сумнарда | | |
|---|---|---|---|
| | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | бакалавр, белгеч яки магистр дипломы белән расланган югары белем |
| "Техник башкаручылар һәм ярдәмче состав артистлары вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме | | | |
| Билетлар буенча контролер | 16 388 | - | - |
| "Мәдәният, сәнгать һәм урта звено кинематографиясе хезмәткәрләре вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме | | | |
| Билет кассалары мөдире | 16 388 | 16 899 | - |

5. Физик культура һәм спорт муниципаль оешмаларының авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазифа атамасы | Аена база оклад күләме, сумнарда |
|---|---|---|
| "Өченче дәрәҗәдәге авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Ветеринария табибы | 17 411 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | II категорияле ветеринария табибы | 17 466 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | I категорияле ветеринария табибы | 17 521 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Әйдәп баручы ветеринария табибы | 17 576 |
| "Дүртенче дәрәҗәдәге авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Баш агроном | 18 302"; |

1.2. 15 нче таблицага түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| "Дүртенче дәрәҗәдәге авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме | | |
|---|---|---|
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | | |
| 1.1. | Баш агроном | 70"; |

1.3. 16 нчы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"16 нчы таблица

Физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары җитәкчеләрнең база окладлары күләмнәре

| Җитәкче хезмәтенә түләү буенча төркем | Күләм күрсәткече билгесе (хезмәткәрләрнең штат саны), кеше | База оклады, сум |
|---|---|---|
| 1 | 20 га кадәр | 23 500 |
| 2 | 21 - 40 | 24 500 |
| 3 | 41 - 60 | 25 500 |
| 4 | 61 һәм аннан күбрәк | 26 000"; |

2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 02 ноябрендәге «Зеленодольск муниципаль районы физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2747 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районында физик культура һәм спорт муниципаль оешмаларының эшче, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләре, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. II бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"II Зеленодольск муниципаль районында физик культура һәм спорт муниципаль оешмаларының эшче, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләре, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең база окладларын билгеләү

1. Зеленодольск муниципаль районы физик культура һәм спорт муниципаль оешмаларының эшче, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләре һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Аена база оклад күләме, сумнарда |
| --- | --- |
| "Беренче дәрәҗәдәге эшчеләрнең гомумтармак һөнәрләре " һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 15 279 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 15 477 |
| "Икенче дәрәҗәдәге эшчеләрнең гомумтармак һөнәрләре "һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 15 618 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 15 792 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 15 970 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 16 501 |

2. Татарстан Республикасы дәүләт физик культура һәм спорт оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Аена база оклад күләме, сумнарда |
| --- | --- |
| 1 | 2 |
| "Беренче дәрәҗәдәге хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары " һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 15 279 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 15 477 |
| "Икенче дәрәҗәдәге хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 15 618 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 15 792 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 15 970 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 16 197 |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | 16 383 |
| "Өченче дәрәҗәдәге хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары " һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 16 573 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 16 766 |

| | |
|---|---|
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 16 963 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 17 164 |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | 17 390 |
| "Дүртенче дәрәҗәдәге хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары " һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 18 302 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 18 502 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 18 702 |

3. Хезмәткәр вазыйфасының һәм һөнәренең эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре һөнәрләренең гомумтармак һөнәри квалификация төркемнәренең, җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфаларының квалификация дәрәҗәләренә туры килүе Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының норматив хокукый актлары нигезендә кабул ителә.

4. Ике эштә берьюлы, шулай ук тулы булмаган эш вакыты шартларында эшләүче хезмәткәрләр хезмәте өчен түләү, эшләгән вакытка пропорциональ рәвештә йә эшләрнең башкарылган күләменә бәйле рәвештә, гамәлгә ашырыла. Төп вазыйфа буенча, шулай ук берьюлы ике эш башкару тәртибендә билгеләнә торган вазыйфа буенча эш хакы күләмнәрен билгеләү, һәр вазыйфа буенча аерым башкарыла".